**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАРЫ**

**2022 елның 28 июнендәге № 69**

**«Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең «Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» 2016 елның 21 апрелендәге 27 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында, шулай ук «Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 01 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» нигезендә 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2016 елның 21 апрелендәге 27 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы

муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

в) үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) санлы финанс активлары, цифрлы валюта, хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр алыш-биреш суммасы алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми керемennән артса һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында.

1.2. 12 өлештә «акцияләр» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Дәүләтшин Раил Хәмит улына йөкләргә.

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башлыгы,**
**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы рәисе** **Н.А.Вазыйхов**